| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ**<br>03.04.2023 | Казан шәһәре | **БОЕРЫК**<br>394-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Арча ш.т.п. «АРЧА» ЖЧЖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында» 2017 елның 9 августындагы 946-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Арча ш.т.п. «АРЧА» ЖЧЖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында» 2017 елның 9 августындагы 946-п номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
03.04.2023 № 394-п
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Арча ш.т.п. «АРЧА» ҖЧҖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында» 2017 елның 9 августындагы 946-п номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

- Боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арча» ҖЧҖ №2 су алу скважинасында санитар саклык зоналарын билгеләү турында

Боерыкның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы нигезендә, 2016 елның 24 июлендәге җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ АРС 01544 ВЭ серияле лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2015 елның 10 июнендәге № 16.11.11.000.Т.001015.06.15 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча ш.т.п. урнашкан «Арча» ҖЧҖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зоналары проекты нигезендә

боерык бирәм:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләрене чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче

кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча ш.т.п. урнашкан «Арча» ҖЧҖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зоналары чикләрен, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә территориядән хуҗалыкта файдалану режимын билгеләргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Арча» ҖЧҖ;
- «Роскадастр» иҗтимагый-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына – санитар саклык зоналарын (алга таба – ССЗ) билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча ш.т.п. «Арча» ҖЧҖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зонасы чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;
- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында.»;

боерыкның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтада:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча ш.т.п. урнашкан «Арча» ҖЧҖнең 2 номерлы су алу скважинасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы»;

1 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1 бүлектәге 1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 3 бүлек өстәргә:

«3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү

чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 09.08.2017 № 946-п боерыгына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 03.04.2023 №394-п боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча ш.т.п. урнашкан «Арча» ҖЧҖ №2 су алу скважинасының санитар саклык зоналары чикләре

Хуҗалык-эчү һәм җитештерү су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын чыгару өчен кулланыла торган гамәлдәге су алу участогы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы, Арча ш.т.п., Вокзал урамы, 1 йорт адресы буенча Арча сөт комбинаты территориясендә урнашкан.

Скважинаның географик координаталары: 56°4′23.64″, 49°52′27.34″ (WGS-84 координаталар системасы).

Санитар саклык зонасының беренче поясы астында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:09:010132:0105.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы.

Скважинаның санитар саклык зонасының беренче поясы чиге 16 м радиус белән билгеләнә;

Санитар саклык зонасының II поясы

Скважинаның ССЗ икенче поясы чиге эллипс белән билгеләнә: агым буенча түбәнгә таба – 100 м, агым буенча өскә таба – 479 м, максималь киңлеге – 203 м.

Санитар саклык зонасының III поясы

Санитар саклык зонасының өченче поясы чиге эллипс буларак билгеләнә: агым буенча аска таба – 102 м, агым буенча өскә таба – 6250 м, максималь киңлеге – 395 м.